КҮРШЕЛӘРДӘ

# Гали авылына — 400 ел!

Татарстан фәннәр Академиясенең Шихабетдин Мәрҗәни исемендәге тарих институтыннан Гали аулына куанычлы язма килеп төште. Бу тарихи белешмә өлкәнең Гали аулына нигез салу турында.

Рус патшалары Михаил Федорович, Иван Алексеевич, Петр Алексеевич имзалаган документлар тупланмасында бүгенге Гали аулына кагылганнары да бар. Бу документта түбәндәге юллар бар:»...отец матери Миняша (Монаша) Гульбастан был пожалован ханом Ибрагимом тарханной грамотой.»

Гөлбостанның атасына Ибраһим хан тарханлык биргән булган. Ә ул заманда тарханлык гаҗәеп зур өстенлекләр биргән адәм баласына. Казан архивларында Гөлбостан — хатынның улы Мөхәммәд –Азизханга бирелгән тарханлык ярлыгы сакланган. Миняшларның нәсел ырыун, шәҗәрәсен тикшереп чыккач, рәсми кәгазьләр шуны күрсәтәләр. Тархан Булат Монашев Кинель елгалары буйлап кондыз ауларга рөхсәт кәгазе ала. Бу документ 1613 ел белән теркәлгән. Әлбәттә бу инде икенче теркәү. 1467-1479 еллардагы Ибраһим хан Монашевларның бабаларының бабаларына ук тарханлык биргән булган бит.

Тарих фәннәре докторы Дамир Исхаков имзалаган һәм мөһер суккан документта Монашевларның ерак бабалары нигез салган Гали аулының тарих башын 1613 елдан башларга тәкъдим ясалган., ә чынында исә Али бабайга тарханлык әле 1479 елны ук бирелә.

Борынгы «Али» рус мохитендә Гали булып түгел, ә «Алькино» булып китә.

2013 елны Галигә 400 ел булачак.Самара дәүләт архивы белешмәләренә караганда, Гали авылы 1871елда Стюхино волостенә керә. Авылда 288 йорт булып, ир-атлар 842 кеше, хатын-кыз 866 кеше була. Барлык җирләр халыкның хосусый милкенә керә. Авылда өч мәчет һәм су тегермәне төзелә. Ә 1900-нче елда инде йортлар саны 304 булып, анда 1708 кеше яши.



Гражданнар сугышы елларында да власть берничә тапкыр кулдан- кулга күчә. 1917 елда авыл Советы оештырыла. Нәбиулла Вәлиуллин рәис булып сайлана. Колхозлашу елларында авыл хуҗалыгы артеле «Кызыл юл» һәм «Тургай» төзелә. Председателе Алтынбаев Хәбибулла була.

1952 елда артельләр кушыла. 1953 елда Шакир углы Фатыйх Тарзеев рәис итеп куела. 1956 елдан «Кызыл юл» колхозы «Тарзеев» колхозы итеп исемләнә. Колхозда кош-корт, эре мөгезле терлек, сарыклар үрчетәләр.

1964 ел. Әсәдулла улы Сәйфулла Сафиуллин бертавыштан колхоз председателе булып сайлана. Ул хуҗалык иткән елларда авылда бик күп эшләр башкарыла. Агач кашыклар, савыт-сабалар ясау өчен остаханәләр ачыла. Бер-бер артлы сөтчелек фермасы өчен биналар төзелә.

Тракторлар ремонтлау остаханәсе барлыкка килә. Асфальт юл салына. Өйләргә газ кертелә. Мәдәният йорты, өч катлы мәктәп бинасы, колхоз идарәсе йорты төзелә. Колхозга яңадан-яңа машиналар, тракторлар кайта. 1989 нчы елга чаклы колхозчы хатын-кызлар тегу остаханәсендә эш киемнәре, бияләйләр тегәләр.

1990-нчы ел. Тормыш шартлары аркасында колхоз бөлгенлеккә төшә. Хөкүмәткә бурычы артканнан арта. Ә 1999-2000 елларда ул бөтенләй таркала. Колхоз таркалса да, авыл халкы чәчүлек җирләрне буш калдырмый, чүп үләне үстерми. Эшмәкәр Наил Баһаутдинов, Камил Исхаков, Әбузәр Гәрәев, Рамил Харисов бу җирләрдә иген, көнбагыш үстерәләр.

Гали авылында бүгенге көндә 705 йорт исәпләнә. Шуларда 2140 кеше яши. Авылның йортлары тирә-яклар өчен үрнәк булып тора, ә халкы бик уңган. Һәр хуҗалык керем өчен суган, кишер, кыяр үстерә. Күп кенә хуҗалыкларда помидор үстерү өчен теплицалар ясалган. Халыкның тормышы яхшы, бу аның тырышлыгына бәйләнгән.

Авылда Расих Латыйпов тарафыннан ачылган колбаса җитештерү цехы «Хәләл» эшләп тора. Алар җитештергән ашамлыкларны илебезнең төрле почмакларында күрергә була. Рамил Мостафин авыл халкы өчен тегермән ачса, Сәйфулла Маннановның ике кибете тормыш-көнкүреш өчен кирәк булган барлык әйберләр һәм азык — төлек белән тәэмин итә.

Наил Баһаутдиновның, Ильяс Арслановның, Камил Руслангалиевның май чыгару цехы уңышлы гына эшләп килә. Гали авылы волосте администрациясе, мәдәният йорты, шифаханә, китапханә, элемтә бүлеге, кәрәзле телефон салоны халыкка хезмәт күрсәтә.

Чуваш авылы Рысайкино белән Гали авылының нәкъ чигендә өч катлы мәктәп бинасы урнашкан. Монда галилеләрнең балалары белем һәм тәрбия алалар. Күптән түгел Гали авылы мәктәбе үзенең 100 еллык юбилеен билгеләп үтте.

**С сайта татарской общины**
**Самарской области**
**www.tatarlarsamara.ru**

**В издательство «Татарская книга» г. Казани вышла книга Рашита Искандарова о татарах Оренбургской области. Наш край — северо-запад Оренбургской области — представлен в ней очень скромно. Так, Асекеевскому району, где большинство населения татары, посвящено 12 страниц книги из 270. А селу Асекеево одна страница. В основном автор опирается на труды Попова, Кузеева и Стрельникова согласно которым Асекеево основано вовсе не татарами. А нынешние татары, оказывается, башкиры.**

**Автору книги претензий нет. Он пользовался источниками, которые были опубликованы еще в прошлом веке. А вот мы — асекеевцы — получается, не помнящие родства. Ничто нам не мешало докопаться до подлинной истории села по примеру алькинцев, а не пользоваться легендами. Они и работать умеют, и историю чтят. Видимо, потому Гали авылы выбрано для проведения общефедерального сабантуя в 2010 году.**

**Редакция газеты поздравляет Расиха Латыпова — председателя культурно-просветительского общества «Туган тел» села Алькино с избранием в исполком Самарской областной татарской автономии. Следует напомнить читателям, что это общество наряду с татарской национально — культурной автономией Асекеевского района, татарским общественным центром «Туган тел» города Бугуруслана, учредили Межрегиональную Ассоциацию татарских национально-культурных объединений Оренбуржья и Самарской области «Бердәмлек». На счету этого объединения уже много добрых дел.**

# Самара татарлары берләште

29 октябрь самара өлкәнең татарлары тарихында кызыл көн булып калачак. Чөнки шул көндә Самара өлкә автономиясе барлыкка килгән. Бу көнне күпләр бик көтеп алган. Чөнки Самара өлкәсендә татарлар күп булса да, аларны берләштерә торган бер оешма һаман юк иде. Беренчедән, Самара, Тольятти, Сызран шәһәрләренең татар — милли автономияләре карар нигезендә Самара өлкә региональ автономиясен төзү буенча оештыру комитеты булдырылды, икенчедән, комитет уз эшен бетергәч, конференция оештырырга да вакыт. Нәкъ агымдагы елның 29 октябрь көнне Самара өлкә милли — мәдәни автономияне оештыру конференциясе узды. Җирле автономияләрнең вәкилләре Самара шәһәренең «Яктылык» мәктәбендә җыелганнар иде. Алар арасында Сызрань, Тольятти, Самара шәһәрләре һәм Гали, Денис, Камышлы авыллары. Җыелышны Русиянең атказанган төзүчесе Вазыйх Мөхәммәтшин алып барды.

Бөтендөнья татар когрессының Башкарма комитеты рәисен, Ринат Закировны, җыелышта катнашучылар игътибар белән тыңладылар. Ринат Зиннур улы Закиров төрле төбәкләрдәге, хәтта чит илдәге татарларның тормышы турында сөйләп күрсәтте. Һәм алар белән чагыштырып, Самара татарларның эшен хуплады.

Автономиянең исполкомына Дания Абрахимова, Вазых Мухаметшин, Якуб Камалов, Фахретдин Канюкаев, Илгиз Колючев, Фархат Махмутов, Минахмет Халиуллов, Рифкат Хузин (Самара), Җамил Валиуллин, Рашид Нурмухаметов, Саубан Рафиков, Рустам Якупов (Тольятти), Илсур Гильманов, Рахимжан Мингалишев (Сызрань), Расих Латыпов (Алькино) керделәр. Яңа автономиянең рәисе булып Халиуллов Миңнәхмет Мухтарович сайланды.

# Татарлыкка бер адым

**Миндә ага татар каны.**
**Мин горур татар булуыма.**
**Мин татарча сөйләшәм.**

Минем өчен бу гади җөмләләр түгел. Бу сүзләр белән минем иртә-кичләрем уза. Үз милләтем белән нык бәйләнгәнмен. Әгәр бүген миннән сорасалар: «Нәрсә өчен гомереңне бирергә әзерсең?». Бердә уйламыйча: «Милләтем өчен», — дияр идем. Юк, мин сезне гомерегезне куярга чакырмыйм, ләкин үзегезне кем икәнлегегезне онытмаска киңәш бирәм. Татар — горур һәм белемле халык булган һәм булырга тиеш.

Мин үзем өчен яңа тойгы, яңа хис ачтым — «татарлык» дип атала ул. Аның нәрсә икәнен сезгә дә аңлатасым килә. Бу мәкаләне укыгач, сез үзегездә дә бу хисне эзләп табырсыз дип ошанам. «Татарлык» ул гади, көнкүреш әйберләрдән җыела.

Беренчедән, карагыз, санагызның эш өстәлендә нинди рәсем тора? Миңарда — «Зәңгәр шәл» спектакленнән төшерелгән фото — милли кием кигән артистлар сәхнәдә тезелешеп утыралар. Сез матур табигать төшкән рәсем куйгансыз? Берүк кәефегез төшмәсен, «татарлык»та әле тагын ничә сыйфатлар бар әле.

Икенчедән, социаль челтәрләр хәзер бик популяр. Әгәр дә сез «Вконтакте» яисә «Одноклассники»ларда утырмыйсыз икән, бу пункт сезнең өчен түгел.

Әгәр көн дә бу сәхифәләргә кереп — чыгып йөрисез икән, уйлап карагыз, сез кайсы төркемнәрдә теркәлгәнсез? «Салават иҗатын хөрмәт итәм» яисә, «Контакт татар телендә» сезнең списокта булса, сез «татарлык»ка илткән юлдан барасыз.

Өченче — телевизор. ТНВ каналы сезнең телевизорда кайсы каналда тора? Беренче? Унынчы? Әллә бөтенләй оныткансызмы? Уйлавымча, монда комментарийлар артык булачак.

Дүртенче — плеерда яки музыкаль үзәгегездә нинди музыка уйный? Илхам Шакировмы әллә Филипп Киркоровмы? Бу пунктта да үзегез нәтиҗә чыгара алырсыз дип уйлыйм.

Бишенчедән, кәрәзле телефонда уйный торган музыка. Сез автобуста барганда телефоныгызны нинди режимга куясыз? Мин, мәсәлән, иң көчле тавышка куям. Яңымдагы пассажирлар «Дөньяда күп нәрсә белдем, син туган тел аркылы»ны аңламасалар да, минем урыс түгелемне сизеп торсыннар!

Алтынчы, автобус темасын дәвам итәбез. Автобуста туган телегездә сөйләшергә ояласыз икән, «татарлык» хисен тоя алалмавыгыз да бар.

Җиденче, яраткан төсегез нинди? Яшел булса — йә сез «татарлык»ка омтыласыз, йә, психологлар фикеренчә, сез тормышта тынычлык эзлисез.

Азакы, һәм, минемчә, иң мөһим сыйфат. Балаларыгызга игътибар бирегез — йөрәк җимешләрегез татарча сөйләшәме? Әгәр, әлегә бала тудырырга өлгермәгәнсез икән, уйлагыз, кызыгызга яки улыгызга киләчәктә ничек дәшерсез һәм ул сезгә нинди җавап кайтарыр?

Әлбәттә, бу кечкенә шаян тест милләтнең тирән мәгънәсенә төшеп бетәлми. Ләкин, минемчә, уйланыр нәрсәләр бар. Әгәр сез бүген үзегезгә: «Ник соң мин һаман чит телендә сөйләшәм», — дип сорау бирсәгез, минем сүзләр юкка узмаган.

**Алсу ХАФИЗ.**
**Тольятти шәһәре.**